ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

08 апрель 2026 ел № 3432

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җир өсте шәһәр пассажир транспортыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 1 октябрендәге 1586 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җир өсте шәһәр пассажир транспортыннан файдалану кагыйдәләрен (алга таба - Кагыйдәләр) кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 8 апрелендәге
3432 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге территориясендә
гомуми файдаланудагы җир өсте шәһәр
пассажир транспортыннан файдалану
кагыйдәләре

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Кагыйдәләр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җир өсте шәһәр пассажир транспортыннан файдалану тәртибен билгели.

2. Кагыйдәләр шәһәрнең бөтен территориясендә гамәлдә һәм гомуми файдаланудагы җир өсте шәһәр пассажир транспортында йөртүләрне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм предприятиеләр, шәхси эшмәкәрләр (алга таба - пассажир йөртүче) һәм күрсәтелгән транспорт төрләреннән файдаланучы пассажирлар өчен мәҗбүри.

3. Әлеге Кагыйдәләр, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җир өсте шәһәр пассажир транспорты (алга таба - транспорт чарасы) эше өчен җавап бирә торган оешманың телефон номерларын һәм адресларын күрсәтеп, барлык автобусларда, трамвайларда һәм диспетчерлык пунктларында урнаштырылырга тиеш.

2 бүлек. Пассажирларның хокуклары һәм бурычлары

4. Пассажир бурычлы:

1) юл йөрү өчен түләүне акчалата башкарырга яки юл йөрү өчен кондукторсыз түләү системасы терминаллары (валидаторлар) аша яки QR-код буенча (тиз түләүләр системасы аша) юл йөрү өчен гамәлдәге тариф нигезендә билет (электрон билет) сатып алу юлы белән кондукторга, ә ул булмаганда, алгы ишектән чыкканда йөртүчегә яки озак вакыт файдаланыла торган юл йөрү билетлары (электрон юл йөрү билеты, электрон бердәм исемле социаль юл йөрү билеты) белән түләргә;

2) озынлыгы, киңлеге, биеклеге 120 сантиметрдан артып киткән кул йөгенең (балалар чанасыннан, балалар коляскасыннан, чехолдагы бер пар чаңгыдан тыш) һәр урыны өчен йөртү бәясен түләргә;

3) транспорт чарасыннан чыкканда контрольне гамәлгә ашыручы затларның беренче таләбе буенча сатып алынган билетны тикшерү өчен күрсәтергә яисә юл йөрү өчен түләү фактын расларга. Юл йөрү өчен банк картасы яисә башка электрон түләү чарасы белән түләгән очракта, пассажир

контролерның таләбе буенча банкның мобиль кушымтасында яисә башка сервиста уңышлы операция турында мәгълүмат күрсәтү, түләү өчен файдаланылган банк картасын (башка түләү чарасын) борт җайланмасына (валидаторга) кабат кую, шулай ук әлеге транспорт чарасында түләү фактын билгеләргә мөмкинлек бирә торган махсуслаштырылган контроль җиһазы аша тикшерү өчен, күрсәтелгән картаны (түләүнең башка чарасын) күрсәтү юлы белән юл йөрү өчен түләү операциясен башкаруны расларга тиеш.

4) контролерлар һәм кондукторлар тарафыннан түләүсез юл йөрү факты, шулай ук гамәлдә булмаган юл йөрү билетларын күрсәтү факты ачыкланганда, юл йөрү, түләнә торган кул йөген йөртү өчен түләргә. Кагыйдәләрнең әлеге пунктының 3 пунктчасында билгеләнгән тәртиптә тикшерү өчен юл йөрү документын (билет) күрсәтүдән, юл йөрү һәм (яки) түләнә торган йөкне йөртү өчен түләүдән баш тарткан очракта, пассажир якындагы тукталыш пунктында автобус, трамвай салоныннан чыгарга тиеш. Әлеге пунктта күрсәтелгән тәртип балигъ булган затның озатып йөрүеннән башка йөрүче 16 яшькә җитмәгән балигъ булмаган балаларга кагылмый, күрсәтелгән балалар транспорт чарасыннан төшерелергә тиеш түгел;

5) юл йөрү ахырына кадәр билет/чек/квитанцияне сакларга;

6) юл йөргәндә пассажирның ташламалы йөрү хокукын раслый торган документлары булырга;

7) гомуми файдаланудагы җир өсте шәһәр пассажир транспорты контролерларына һәм кондукторларга тикшерү өчен барлык төр юл йөрү билетларын, шулай ук ташламалы йөрү хокукына документларны ачып күрсәтергә (кулга бирергә);

8) җәмәгать тәртибен сакларга, әлеге кагыйдәләрне үтәргә, шулай ук үзара әдәпле булырга һәм күчмә составка сак карарга;

9) транспорт чарасы тулысынча туктаганнан соң, даими йөртүләр маршрутының билгеләнгән тукталыш пунктларында гына транспорт чарасы салонына керергә һәм аннан чыгарга;

10) пассажирлар тулысынча төшеп беткәннән соң, транспорт чарасының барлык ишекләре аша транспорт чарасы салонына керергә;

11) транспорт чарасы салоныннан алгы ишек аша чыгарга;

12) пассажирларның таләбе буенча аларны төшерү өчен, транспорт чарасын «таләп буенча» тиешле тукталыш пунктында туктату кирәклеге турында кондукторга яки йөртүчегә алдан хәбәр итәргә;

13) транспорт чарасын тукталыш пунктларында тоткарламаска;

14) маршрутның соңгы тукталышына килгәч, транспорт чарасы салонын бушатырга;

15) транспорт чарасы салонында төтен, көйгән яки янган ис барлыкка килсә, бу хакта кичекмәстән йөртүчегә яки кондукторга хәбәр итәргә;

16) транспорт чарасы салонында күзәтүчесез калган чит предметлар табылганда:

- бу турыда кичекмәстән йөртүчегә яки кондукторга хәбәр итәргә;
- аларны юкка чыгару яки күчерү буенча мөстәкыйль гамәлләр кылмаска.

5. Транспорт чарасы салонда булганда пассажирлар тиеш:

1) инвалидларга, өлкән яшьтәге затларга, йөкле хатын-кызларга, балалы пассажирларга урын бирергә;

2) ишеккә сөялмәскә;

3) салонга кергәндә аркадагы сумкаларны (рюкзакларны) салырга һәм аларны кулда тотарга;

4) чыгу өчен алдан әзерләнергә, кергәндә һәм чыкканда чиратны сакларга, пассажирларның керүенә һәм чыгуына комачауламаска;

5) хәрәкәт иткәндә тоткаларга яки асылмалы каеш тоткаларга тотынырга;

6) кул йөгенең бөтенлеген һәм сакланышын тәэмин итәргә;

7) салонда чисталык сакларга, транспорт чаралары җиһазларының сакланышына сак карарга.

6. Пассажирлар хокуклы:

1) аерым утыру урыннарына утыртмыйча, җиде яшьтән өлкән булмаган балаларны үзең белән бушлай йөртергә;

2) үзең белән бушлай йөртергә:

- озынлыгы, киңлеге һәм биеклеге 120 сантиметрдан артык булмаган бер урыннан артмаган кул йөге;

- озынлыгы, киңлеге һәм биеклеге 120 сантиметрдан артык булмаган бер урыннан артмаган чехолдагы бер пар чаңгы, балалар чанасы, балалар коляскасы;

- Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н Боерыгы белән билгеләнгән форма һәм тәртип буенча бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, юл күрсәтүче этне;

- күрсәтелгән читлекләрнең зурлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 1 октябрендәге 1586 номерлы Карары белән расланган Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләренең (алга таба - пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләре) 36 пунктында каралган таләпләргә җавап бирсә, төбе тоташ булган читлекләрдәге (кәрзиннәрдәге, тартмалардагы, контейнерлардагы) хайваннарны һәм кошларны;

3) бирелгән транспорт чарасының төзек булмавына, авариягә яки башка сәбәпләргә бәйле рәвештә юлда бару туктатылган очракта, пассажирлар сатып алынган билетны йөртүче күрсәткән башка транспорт чарасында юл йөрү өчен файдаланырга хокуклы. Пассажирларны башка транспорт чарасына күчереп утырту юл йөрү өчен билет сатып алынган транспорт чарасының кондукторы яки йөртүчесе тарафыннан оештырыла;

4) пассажирларны борчымый торган шартлар үтәлгәндә, бер урынлык багаж ташуга билгеләнгән тариф нигезендә түләп, арткы туплау мәйданчыкларында борынчыгы һәм муенчаклы бавы булган этләр йөртергә.

7. Пассажирларга тыела:

1) трамвайда, автобуста юл йөрү, кул йөген йөртү өчен түләмичә йөрергә;

2) транспорт чарасының чыгып торган өлешләрендәге баскычларда йөрергә;

3) пассажирларны, утыргычларны, транспорт чарасы салонын пычратырга мөмкин булган азык-төлек, шулай ук багаж һәм кием белән салонга керергә;

4) салонда исерек хәлдә булырга, алкогольле эчемлекләр эчәргә, наркотик чаралар кулланырга;

5) транспорт чарасы салонында тәмәке тартырга һәм ачык уттан, пиротехник җайланмалардан (фейерверклардан, петардлардан) файдаланырга;

6) транспорт чарасына зыян китерергә;

7) тәрәзәләрдән башны чыгарырга;

8) утыру урыннарыннан аларның турыдан-туры билгеләнешенә туры килмәгәнчә файдаланырга;

9) тормоз һәм ишекләрне ачу механизмнарын эшләтеп җибәрергә, шулай ук, бәхетсезлек очракларын булдырмау кирәклегеннән тыш, ишекләрне ябуга һәм ачуга комачауларга;

10) йөртүче кабинасында булырга, хәрәкәт иткәндә аның игътибарын читкә юнәлтергә һәм аның белән сөйләшергә;

11) кул йөге составында яман исле һәм куркыныч (тиз янучан, шартлаучан, агулаучан) матдәләр, чехолсыз һәм төргәксез салкын һәм утлы корал, шулай ук транспорт чарасын яки пассажирларның киемнәрен пычрата торган әйберләр (предметлар) ташырга;

12) утыру өчен билгеләнгән урыннарда, утыргычлар арасындагы үтү юлында, транспорт чарасына керү яки чыгу урыны, шул исәптән авария чыгу урыны янында кул йөген урнаштырырга;

13) транспорт чарасы салонын чүпләргә һәм пычратырга;

14) йөртүчегә пассажирларның керүен һәм чыгуын күзәтүне кыенлаштырып, салонның алгы ишеге янында торырга;

15) транспорт чарасында «Кондуктор урыны» мәгълүмат билгесе куелган махсус билгеләнгән урынга утырырга.

8. Әлеге кагыйдәләрне бозу гамәлдәге законнар нигезендә административ җаваплылыкка тартуга китерә. Түләүдән баш тарту пассажирны гомуми файдаланудагы җир өсте шәһәр пассажир транспортында билетсыз йөргән һәм түләнмәгән кул йөген йөрткән өчен штраф түләүдән азат итми.

3 бүлек. Йөртүченең һәм кондукторның хокуклары һәм бурычлары

9. Йөртүче бурычлы:

1) пассажирларны утырту һәм төшерү тәмамланганнан соң ишекләр ябык булганда гына транспорт чарасын тукталыш пунктыннан кузгатырга;

2) һәр туктальш пунктының һәм аннан соңгы туктальш пунктының, күчеп утыру урыннарының исеме турында пассажирларга ике дәүләт телендә хәбәр итәргә, ә маршрут үзгәргәндә, бу хакта һәр туктальшта игълан итәргә, башка кирәкле мәгълүматны, шул исәптән юл йөрү өчен түләү тәртибе турында, мәгълүмат бирүче һәм (яисә) махсус чаралар ярдәмендә хәрәкәт иминлеге турында мәгълүмат бирергә;

3) пассажирларның таләбе буенча аларны утырту (төшерү) гамәлгә ашырыла торган тукталыш пунктлары турында транспорт чарасындагы пассажирларны алдан ук кисәтергә;

4) кондуктор булмаганда, билет/чек/квитанция биреп, юл йөрү һәм кул йөге йөртү өчен түләүне кабул итәргә. Ташламалы категориядәге пассажирларның юл йөрү билетын тикшерергә;

5) билгеләнгән маршрут хәрәкәте схемасын һәм гомуми файдаланудагы җир өсте шәһәр пассажир транспорты хәрәкәтенең расланган расписаниесен үтәргә;

6) маршрут схемасында каралган җиһазландырылган тукталыш пунктларында, штаттан тыш хәлләрдән тыш яисә пассажирларның таләбе буенча аларны утырту (төшерү) гамәлгә ашырыла торган тукталыш пунктларында пассажирларны утыртуны һәм төшерүне гамәлгә ашырырга;

7) пассажирларның таләбе буенча аларны утырту (төшерү) өчен транспорт чарасын туктатуны гамәлгә ашырырга, әгәр:

- транспорт чарасындагы пассажир кондукторга яки йөртүчегә транспорт чарасын тиешле тукталыш пунктында туктату кирәклеге турында алдан ук хәбәр итсә;

- тукталыш пунктында транспорт чарасы килүен көтеп торучы затлар булса;

8) билгеләнгән маршрутның барлык тукталыш пунктларында мәҗбүри тукталып, транспорт чарасының техник характеристикасында күрсәтелгән иң чик сыйдырышлыгы нигезендә пассажирларны йөртергә;

9) пөхтә тышкы кыяфәтле булырга, шәһәр транспорты салонында чисталык һәм тәртип сакларга, пассажирлар белән әдәпле һәм корректлы булырга;

10) контроль билетларны, транспорт чарасы тулысынча туктаганда, тукталыш пунктларында һәм мәҗбүри тукталышларда гына сатарга;

11) транспорт чарасы салонында пассажирлар оныткан әйберләр, документлар, акча һәм башка кыйммәтле әйберләр табылганда, аларны маршрутның соңгы станциясе, депо, предприятие диспетчерына тапшырырга;

12) күчмә состав салонында тормыш һәм сәламәтлек өчен куркыныч тудырырга мөмкин булган предметлар, шулай ук көйгән, төтен, янган ис, электр тогы тәэсире булу турында ачыкланганда яки пассажирлардан мәгълүмат алынганда, транспорт чарасының хәрәкәтен туктатырга, пассажирларны эвакуацияләргә, кондуктор белән бергә транспорт чарасыннан чыгарга һәм ашыгыч хезмәтләр телефоны аша бу хакта диспетчерга хәбәр итәргә;

13) пассажирга ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү кирәк булган очракта транспорт чарасын туктатырга, ашыгыч ярдәм чакыртырга һәм үзәк диспетчерга хәбәр итәргә;

14) пассажирлар әлеге Кагыйдәләрне үтәмәгән һәм хокук бозулар кылган очракта, транспорт чарасын туктатырга һәм эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итәргә яки хокук бозучыларны төшереп калдыру чараларын күрергә;

15) маршрутның соңгы тукталышына килгәч, пассажирлар калдырган предметлар булуга салонны карап чыгарга, транспорт чарасының техник торышын тикшерергә. Барлык ачыкланган төзексезлекләр яки зыян күрүләр турында диспетчерга хәбәр итәргә;

16) коляскадагы инвалидларны, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган инвалидларны һәм күрү һәм ишетү сәләте бозылган затларны куркынычсыз утырту һәм төшерүне, шулай ук юл йөрүнең уңайлы шартлары белән тәэмин итәргә;

17) йөртүченең башка бурычлары аның вазыйфаи инструкциясе һәм техник эксплуатация кагыйдәләре белән билгеләнә.

10. Йөртүче (яки кондуктор) хокуклы:

1) яман исле һәм куркыныч (тиз янучан, шартлаучан, агулаучан) матдәләр, чехолсыз һәм төргәксез салкын һәм утлы корал, шулай ук транспорт чарасын яки пассажирларның киемнәрен пычрата торган әйберләр (предметлар) йөртергә тырышкан очракта, пассажирның юл йөрүенә каршы килергә;

2) әгәр аларның составына керә торган әйберләрнең үзлекләре яки төргәкләре әлеге кагыйдәләр таләпләренә җавап бирмәсә, әгәр аны транспорт чарасында урнаштыру пассажирларның транспорт чарасына керүенә, пассажирларның транспорт чарасыннан чыгуына комачауласа, пассажирның кул йөген йөртүенә каршы килергә;

3) пассажирда гамәлдә булмаган юл йөрү билеты яки ташламалы юл йөрү хокукы бирә торган документ ачыкланганда, пассажир юл йөрү өчен яки балаларны һәм кул йөген йөртү өчен түләүдән баш тартканда, әлеге яки киләсе тукталышта транспорт чарасы салоныннан чыгып китүне таләп итәргә.

11. Йөртүчегә тыела:

1) билет/чек/квитанция бирмичә, пассажирлардан юл йөрү һәм кул йөге йөртү өчен түләү алырга;

2) ишекләре ябык булмаган транспорт чарасының хәрәкәт итүен гамәлгә ашырырга;

3) юл яки маршрут кәгазенә язылган затлардан тыш, чит затларны транспорт чарасы кабинасында йөртергә;

4) транспорт чарасында тәмәке тартырга, транспорт чарасы хәрәкәт иткәндә, куллар ярдәменнән тыш сөйләшүләр алып барырга мөмкинлек бирә торган техник җайланма белән җиһазландырылмаган телефоннан файдаланырга;

5) балигъ булган затның озатып йөрүеннән башка йөрүче 16 яшькә җитмәгән балигъ булмаган балаларны транспорт чарасыннан төшереп калдырырга;

6) транспорт чарасын тукталыш пунктыннан читтә туктатуны гамәлгә ашырырга.

12. Кондуктор бурычлы:

1) пөхтә тышкы кыяфәтле булырга, шәһәр транспорты салонында чисталык һәм тәртип сакларга, пассажирлар белән әдәпле һәм корректлы булырга;

2) бер тапкыр кулланыла торган билетлар сатып алу кирәклеге турында искәртергә, билет/чек/квитанция биреп, юл йөрү һәм кул йөге йөртү өчен түләүне кабул итәргә. Ташламалы категориядәге пассажирларның юл йөрү билетлары һәм ташламалы юл йөрү хокукын бирә торган документлары булуын тикшерергә;

3) транспорт чарасы салонында шикле предметлар табылганда, бу хакта кичекмәстән йөртүчегә хәбәр итәргә;

4) пассажирлар транспорт чарасына кергәндә түләү алырга һәм юл йөрү һәм кул йөге йөртү өчен бер тапкыр бирелә торган билетлар бирергә; пассажирларның юл йөрү өчен түләүләре булуын тикшерергә;

5) пассажирларга инвалидлар, өлкән яшьтәге затлар, йөкле хатын-кызлар, балалы пассажирлар өчен билгеләнгән урыннарны бушатырга тәкъдим итәргә;

6) аудиоинформатор булмаганда яки төзек булмаганда, һәр тукталыш пунктының исемен игълан итәргә, ә маршрутны үзгәртергә мәҗбүр булганда - бу хакта һәр тукталыш пунктында хәбәр итәргә.

13. Кондукторга тыела:

1) билет/чек/квитанция бирмичә, пассажирлардан юл йөрү һәм кул йөге йөртү өчен түләү алырга;

2) транспорт чарасында тәмәке тартырга, транспорт чарасы хәрәкәт иткәндә телефоннан файдаланырга;

3) пассажирларның шәхси документларын алырга, пассажирларның ихтыярына каршы аларны транспорт чаралары салоны эчендә тоткарларга. Балигъ булган затның озатып йөрүеннән башка йөрүче 16 яшькә җитмәгән балигъ булмаган балаларны транспорт чарасыннан төшереп калдырырга.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева